ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**2019 ел** «10» декабрь **№** 1087

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 21 сентябрендәге 925 номерлы “Муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, "Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында" 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 21 сентябрендәге 925 номерлы карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында Нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга кагылышлы түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча актлар проектларының җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш:

1) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм җирлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

2) җирлек халкын элемтә, җәмәгать тукלануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3) буш вакытны оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
4) җирле халыкның традицион сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, җирлектә халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;
5) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясендә урнашкан территорияне планлаштыру буенча җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән документацияне раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектлар файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү, җирлекләрне шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм җирлек чикләрендә җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу;
6) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;
7) җирлек чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру;
8) махсус икътисадый зона территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.»;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Аклар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәгеләргә карата үткәрелми:

1) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары.»;

3) 19 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) акт проектының конкуренция торышына йогынтысын анализлау; »

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Профильле бүлекчәнең җайга салу йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәдә әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр актында булу, акт проектын кабул итүнең максатка ярашлы булмавы яисә аны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр бирелгәнлеге турында нәтиҗә ясалган очракта, әзерләүче кисәтүләрне юкка чыгарырга тиеш.

Әгәр әзерләүче йомгаклауда китерелгән профильле бүлекчә нәтиҗәләре расланмаган дип саный икән, әзерләүче тарафыннан килештерелгән позициягә ирешү максатларында профильле бүлекчә белән килештерү процедураларын уздырыла. Килештерелгән позициягә ирешмәгән очракта, әзерләүче тарафыннан беркетмә рәсмиләштерелә, ул әзерләүче җитәкчесе (яки аның урынбасары) һәм профильле бүлекчә җитәкчесе (яки аның урынбасары) тарафыннан имзалана.

Алга таба проект буенча материалларга акт проектын кабул итү процедурасын гамәлгә ашырганда, килештерү процедуралары нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән беркетмә мәҗбүри тәртиптә өстәлеп куела.

Акт проектын әзерләүдән баш тарту яисә аны эшләп бетерү турында карар кабул ителгән очракта, әзерләүче җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә һәм акт проекты буенча тәкъдимнәр җыелмасын алган көннән алып 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, тиешле мәгълүматны рәсми сайтка урнаштыра.

Әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр акт проектында ачыкланмаган очракта, әзерләүче акт проектының йомгаклау редакциясен әзерли, шулай ук акт проекты буенча ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу яисә кире кагу сәбәпләре турындагы мәгълүматны, җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә алган көннән алып 15 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрә.».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Мөхәрәмовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин